| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БУРУНДУКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧМУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БОРЫНДЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 елның 20 октябре Борындык ав. № 39

Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге территориясендә урнашкан каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларының реестрын һәм урнаштыру схемасын раслау турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Җитештерү һәм куллану калдыклары турында" 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль законның 13.4 статьясындагы 4 пункты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 31 августындагы 1039 номерлы карары белән расланган каты коммуналь калдыкларны туплау урыннарын (мәйданчыкларын) һәм аларның реестрын алып бару кагыйдәләре нигезендә, Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны туплау урыннары реестрын расларга (1 нче кушымта).
2. Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын урнаштыру схемасын расларга (2 нче кушымта).
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырырга http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Борындык авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Борындык авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы А.Р.Гайнетдинов

Кайбыч муниципаль районы
Борындык авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2023елның 20 октябрендәге
39 номерлы карарына
1 нче кушымта

## Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны туплау урыннары реестры

| N | Контейнер мәйданчыгының милекчесе (хуҗасы) | Контейнер мәйданчыгының урнашу урыны | Контейнерлар саны (данә) | Контейнерларның күләме (м3) | мәйданчыкка җыела торган каты көнкүреш калдыклары барлыкка килү чыганаклары |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге Башкарма комитеты | ТР, Кайбыч районы, Борындык авылы, Ленин урамы | 2 | 2 | Борындык авылы, Ленин урамы |
| 2 | Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге Башкарма комитеты | ТР, Кайбыч районы, Борындык авылы, М.Рамил урамы | 2 | 2 | Борындык авылы, М.Рамил урамы |
| 3 | Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге Башкарма комитеты | ТР, Кайбыч районы, Шүширмә авылы, Кооператив урамы | 2 | 2 | Шүширмә авылы Кооператив урамы |

каты коммуналь калдыкларны туплау урыннарының (мәйданчыкларынын) урнашу урыны турында мәгълүматлар;

каты коммуналь калдыкларны туплау урыннарының (мәйданчыкларынын) техник характеристикалары турында мәгълүматлар;

каты коммуналь калдыкларны туплау урыннары (мәйданчыклары) милекчеләре турында мәгълүматлар;

каты коммуналь калдыкларны туплау урынында (мәйданчыгында) туплана торган каты коммуналь калдыклар барлыкка килү чыганаклары турында мәгълүматлар.

Кайбыч муниципаль  районы
Борындык авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2023е. 20 октябрендәге
39 номерлы карарына
2 нче кушымта

Борындык авылы янында каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнер мәйданчыкларын урнаштыру схемасы



Шүширмә ав. каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнер мәйданчыкларын урнаштыру схемасы

